СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

15 июль, 1998 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 80 (8237) | Бәясе билгеләнгәнчә

## КОРЫ КӨННӘРНЕҢ КАДЕРЕН БЕЛИК

### “УҢЫШ - 98” МАТБУГАТ ҮЗӘГЕ ХӘБӘР ИТӘ

***Күпьеллык үләннәрнең беренче каты чабылып бетте дияргә мөмкин инде, шуңа күрә ул мәйданнардан туплана торган коры печәннең әллә ни ишәясе калмады. Атна башына ул төр запас 8 мең тоннадан артып китте. Соңгы ике - өч көндә Мичурин исемендәге, “Игенче”, “Татарстан”, “Чирмешән”, Кузнецов исемендәге, “Агрохимсервис” ярдәмче хуҗалыкларында печән запасын чагыштырмача ярыйсы гына арттыра алдылар.***

***Сенаж бу көннәрдә нигездә “Кондырча”, “Киекле”, Мичурин исемендәге, “Рассвет”, Муса Җәлил исемендәге хуҗалыклар исәбенә ишәйде. Аларның беренчесендә базда 2 мең тоннадан артыграк яшел масса бар, бикүлелеләр бер көндә 100 тонна сенаж салдылар. Әмма сенаж салуга тотынган хуҗалыклар саны артмый әле һәм район буенча бу төр азык запасы дүшәмбегә 7200 тонна тирәсе иде. Витаминлы үлән оны агрегатларының җитештерүчәнлеге дә әллә ни югары түгел. “Кондырча”да бу төр азыкны 2 тонна туплап куйдылар инде, ә менә 17 агрегат белән бер көндә ясалган барлык үлән оны 12 тонна гына һәм кайбер хуҗалыклардан мәгълүматларның ике көннекен бергә кушып бирелүен дә искә алсак, АВМнарның көнлек җитештерүчәнлеге гомумән алганда канәгатьләнерлек түгел.***

***Дару үләннәрен элеккечә үк “Рассвет”та мулдан тупларга тырышалар. Яфрак азык запасы 750 тонна чамасы булып, соңгы бер көндә бу эш белән “Татарстан”, Кузнецов исемендәге, Синдряков исемендәге һәм Хафизов исемендәге хуҗалыкларда гына шөгыльләнделәр.***

***Уҗым чәчү өчен җир әзерләү кебек мөһим эшкә тотынган хуҗалыклар саны элеккечә үк. Соңгы бер көндә “Родина”, Хафизов исемендәге, “Татарстан”, ”Төрнәс”,”Заветы Ильича” хуҗалыкларында барлыгы 200 гектар чамасы җир эшкәртелде. Ә кимендә 25 мең гектарда уҗым чәчәсе булуын исәпкә алсак, мондый темплар гына һич канәгатьләндерергә тиеш түгел. Өстәвенә, алты хуҗалыкта ул эшкә һаман да тотынмаганнар әле. Мәйданнарны терлек азыгы культураларын кабат чәчү били дияр идек - бу арада ул эш белән дә әллә ни шөгыльләнүче юк.***

## Татарстан Дәүләт Советы сессиясендә

10 июльдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче пленар сессиясе үзенең эшен дәвам иттерде.

Сессия, Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев тәкъдим иткән кандидатураны яклап, Республика Премьер - министры итеп моңарчы финанс министры булып эшләгән **Рөстәм Нургали улы МИННЕХАНОВ**ны раслады.

Сессия Татарстан эчке эшләр министры итеп **Әсгат Әхмәт улы СӘФАРОВ**ны, финанс министры итеп моңарчы министрның беренче урынбасары - “Ак Барс” банкы идарәсе рәисе булып торган **Роберт Ренат улы МУСИН**ны раслады.

Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин тәкъдиме белән сессия Дәүләт Советы Рәисенең төп эшеннән аерылмаган өченче урынбасары итеп халык депутатларының Алексеевск район Советы рәисе, хакимият башлыгы **Алексей Иванович ДЕМИДОВ**ны сайлады.

Дәүләт Советы Секретаре итеп Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясе рәисе урынбасары **Валентина Николаевна ЛИПУЖИНА** сайланды.

Башка оештыру мәсьәләләреннән тыш, сессиядә Татарстан Республикасының 1997 елгы республика бюджетының үтәлеше турында отчет расланды, агымдагы елның алты аенда республика бюджетын үтәүнең барышы турындагы мәгълүмат игътибарга алынды.

Сессиядә Татарстан Республикасының Җир кодексы кабат каралды һәм Президент искәрмәләре белән кабул ителде.

Сессиядә башка күп кенә мөһим мәсьәләләр дә тикшерелде.

Дәүләт Советы Сессиясе эшендә Татарстан Республикасы Президенты **М.Ш.ШӘЙМИЕВ** катнашты. Сессияне Дәүләт Советы Рәисе **Ф.Х.МӨХӘММӘТШИН** алып барды.

## АВМ ЭШТӘ

"Үрнәк" КХАсының Биляр Озеро авылы механизаторлары терлек азыгын әзерләүгә быел җаваплырак карарга тырышалар. Булган печәннәрне җыюны да үзвакытында башкарырга өлгерделәр. Бүген хуҗалыкта витаминлы үлән оны әзерләү агрегаты да зур тоткарлыкларсыз эшли.

Аңа җаваплы кешеләр башлыча күп еллар буе шунда эшләп, байтак тәҗрибә туплаганнар. Петр Владимирович Благоразумов, Анатолий Николаевич Ворухин һәм яшьләр - Роберт Йөзмехәммәтов белән Виталий Никифоров тырышлыгы ярдәмендә быел хуҗалык малларына витаминлы үлән онын җитәрлек әзерләп куярга ниятли.

## БАР ЭШТӘ ДӘ ӨЛГЕРЛӘР

Хафизов исемендәге КФХАда кукуруз чәчелгән җир 400 гектардан артык мәйданны били. Быел аны чәчү, рәт араларын йомшарту һәм тамырдан тукландыру эшләрен беренче кооператив механизаторлары Әхтәм Насыйбуллин, Якуп Кәримов, Иван Мортазин, Вячеслав Сибулатов, ярдәмче буларак Илшат Сәмигуллин бик тырышып башкардылар. Ә хәзер егетләр печән әзерләүдә өлгерләр.

**Т.ДЕРБЫШЕВ,**
**хәбәрче.**

*Балаларның җәйге ялы*

## АНАПАДАН ХАТЛАР КӨТЕГЕЗ

**Шимбә көнне районыбыз мәктәпләреннән җыелган 40 яшүсмер бала ерак юлга кузгалды. Алар балаларның Россия күләмендәге ял лагерьларыннан берсендә - Анапа шәһәрендә 18 көн ял итәчәкләр.**

Балаларга юл алдыннан тормыш иминлеге кагыйдәләре хакында инструктаж үткәрелде. Араларында җитәкче буларак 4 өлкән кеше, шул исәптән 1 табиб та булган зур төркем 2 автобуста Казанга, аннан поезд белән Кара диңгез буена юл алды.

## «УЯВ» УЗДЫ

Чуваш фольклор коллективларының киң катнашында уза торган "Уяв"ны Нурлатның үзәк мәйданында да, стадионда да үткәргән чаклар булды. Дөрес, ул елларда да яраткан бәйрәменә халык күп җыела, хәтта республиканың башка районнары һәм шәһәрләреннән, күрше Самара өлкәсеннән дә кунаклар - тулы коллективлар килә торган иде. Ә менә быел бәйрәмне чын авылча иттереп, авыл җирендә үткәрергә карар кылынды, һәм узган якшәмбедә Питрау көнне үткән бәйрәм мондый фикернең бик отышлы булганлыгын ачык итеп раслады. Вишневая Поляна авылыннан ерак түгел, Чирмешәннең уң як ярындагы урман буенда, табигатьнең гүзәл урынында үткән ул бәйрәмне тамаша кылырга районның барлык авылларыннан да килгәннәр, Нурлаттан рус, татар милләтеннән халык та күп иде. Соңгы елларда "Уяв"ка бу кадәр халык җыелганы хәтердә юк әле.



Алдан игълан ителгән программада каралган йоланы үтәгәннән соң, фольклор коллективлары бер - бер артлы бәйрәм мәйданына җыелдылар. Аларны биредә башта Мичурин исемендәге хуҗалык җитәкчесе И.Н.Мөхәммәтов, аннан район хакимияте башлыгының социаль - мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Х.Абдуллин кайнар котладылар. Казаннан килгән журналистлар - Татарстан радиосының чуваш редакциясе бүлегеннән Петр Миров, "Сувар" газетасы баш мөхәррире Александр Ивановның да милләттәшләренә әйтер сүзләре бар иде.





Аннан фольклор коллективларының чыгышлары китте. Борынгы да, заманча да, моңлы да, дәртле дә җырлар, биюле такмаклар - барысы да бик мулдан булды ул көнне. Фольклор коллективлары да аз түгел иде. Андреевка, Аксумла, Богдашкино, Егоркино, Урта Камышлыдан, Нурлаттан “Родник” фольклор коллективлары, кайсыларының балалар фольклор коллективлары да чыгыш ясады бу көнне.

Ә бәйрәм үзләрендә узып та аңа махсус чакыру алмаган Абляскино һәм Вишневая авылларының фольклор коллективларының урында, экспромт рәвешендә генә оешып та, менә диگән иттереп чыгыш ясаулары нур өстенә нур булды. Заманында авылда "Уяв" оештырып йөргән пенсионер Устьинья Андреевна Кульметьеваның йөрәгендә дәрт - дәрман бетмәгән икән әле һәм аның инициативасына авылдашлары гына түгел, шушы бәйрәмгә Нурлаттан, читтән килгән якташлары да кушылып китте.

Елдагыча, бәйрәмдә ялгыз чыгышлар да аз булмады. “Чуваш сандугачлары” - Аксумладан Ирина Семенова һәм Сергей Ендиряков, Нурлаттан Ирина Сафандеева һәм Надежда Митянина, шулай ук Аксумланың яшь сандугачы Елена Акмуллина һәм башкаларның дәртле җырларына бөтен мәйдан диярлек кушылып биеп - җырлавын карап торуы гына да искитмәле иде.

Бәйрәмне аның елдагы хуҗалары Галина Корчукова белән Александр Ильин бар күңелләрен биреп алып бардылар. Бәйрәмне әзерләгән һәм оештырган район мәдәният бүлеге һәм Нурлат мәдәният йорты хезмәткәрләренең аны тиешле югарылыкта үткәрү өчен күп көч куйганлыкларын билгеләп үтми мөмкин түгел.

Гадәттәгечә, бәйрәмдә милли ризыклардан табыннар да, традицион сыра да мулдан иде. Халыкка шул ук көнне үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтәргә чыккан сәүдә хезмәткәрләре дә хезмәт күрсәтте. Кыскасы, "Уяв"ның быелгысы тагын да массовыйрак төстә, тагын да оешканрак тәртиптә һәм тагын да кызыклырак булып үтте.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**
**Н.АЗИЗОВ** һәм **автор** фотолары.

Үткән бәйрәмнән соң

# КООПЕРАЦИЯНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ БАР

***1930 - 40нчы елларда аның исеме “кооперация” иде. Ә хәзер - кулланучылар җәмгыяте. Әмма ничек кенә аталмасын, халыкны беренчел ихтыяҗ товарлары белән тәэмин итү, пайчылар мәнфәгатен кайгырту аның төп бурычы булып калды. Тик соңгы вакытта икътисадның базарга борылышы җәмгыятьнең яңа, кырыс конкуренция шартларында эшләүгә зур кыенлыклар белән яраклашуын ачыклады.***

***Шуңа да халыкара кооператорлар көне уңаеннан без райпо рәисе М.С.МОРАТОВ белән ирешелгән уңышлар, югары күрсәткечләр турында түгел, ә бихисап проблемалар, аларны хәл итү ысуллары хакында сөйләштек.***

**- Минталип Салихович, сүзне бүгенге көндә район кулланучылар җәмгыятенең структур төзелеше, гомуми хәленә характеристика бирүдән башлыйк әле.**

- Кулланучылар җәмгыяте җәмәгать туклануы предприятиесен, хәзерләүләр конторасын, азык - төлек комбинаты һәм хуҗалык исәбендәге авыл сәүдә предприятиесе кебек катлаулы, четрекле тармакларны үз эченә ала. Һәркайсының үз исәп - хисап счеты, үзенең еллык планы. Әйе, былның беренче кварталында райпо тулаем алганда аны үти алмады - чөнки - җылылык, ут, су һәм башкалар өчен җыелган бурычларны түләү чоры эләгеп безне төпкә утыртты дияргә була. Ә икенче кварталны хәзерләүләр конторасыннан башка тармаклар керем белән төгәлләделәр.

### МАХСУС БЕЛЕШМӘ

*Җәмәгать туклануы* ***предприятиесе:*** *күптән түгел биредә кондитер цехы ачылуы товар әйләнешен арттыруда үтемле чара булды. Шулай ук “Колос” ресторанының да предприятиенең җитештерүчәнлегендә өлеше зур. Сезонына карап анда клиентлар ихтыяҗына якын килеп эшләргә омтылалар, мәсәлән, хәзер ресторан төнге сәгать 2гә кадәр эшли. Читкә чыгып сәүдә итүләр оештырыла.*

***- Азык - төлек комбинаты*** *продукциясенең сыйфаты күпләрнең продукциясенә конкурент булырлык, -ди М.Моратов,- тик менә әлегә кадәр аны сатып алучы игътибарын җәлеп итәрлек итеп тәкъдим итү мөмкинлеге юк. Киләчәктә нәкъ шул юнәлештә эшләү, заманча фасовкалау җайланмалары сатып алу күздә тотыла.*

*Төрнәс пекарнясы әйбәт эшләп килә, аның продукциясен халык һәрвакыт көтеп ала.*

***Хәзерләүләр конторасы:*** *бүген ул райпода иң сүлпән, артка сөйрәүче тармак. Дөрес, анда пландагы 22 төр продукция җитештерелә, күрсәткечләр дә планны үтәүгә якын, әмма болар һәммәсе дә специфик кыенлыкларны (мәсәлән, ветеринария эшкәртүе, биохимик анализлар ясау контора өчен аеруча кыйммәткә төшә) үтеп кенә гамәлгә ашырыла. Хәлне төзәтү йөзеннән җитәкчелек контораның исәп - хисап счетын үз кулына ала, элеккечә бартер ысулы белән эшләүне бетереп, халыкка продукция өчен тере акча бирергә ниятли. Алга таба тагын да кискенрәк адымга - контораны чикләнгән җаваплылыктагы ширкәт итеп үзгәртергә җыена.*

***Хуҗалык исәбендәге авыл сәүдә предприятиеләре:*** *районда барлыгы 115 кибет бар. Шуларның 30лабы халкы аз санлы, яки районның иң ерак почмакларында хезмәт күрсәткәнгә, чыгымнар бермә - бер арта.*

*Халыкта тере акча юк, ә пенсионерлар керемен бөтен гаилә көтеп тора. Билгеле ки, коммерсантлар мондый җирдә йөрми, транспорт чыгымнары да зур, ихтыяҗ да мөмкинлекләр белән тәңгәл килми. Ә менә райпо кибете авылга хезмәт күрсәтү кебек изге бурычын үтәүдә нык тора әлегә.*

*Үткән елларда 22 кибет үзара килешү шартларында арендага бирелеп тора, тик бу ысул да файда китерми, бүген Нурлатта бары тик өч кибет кенә арендада. Соңгы вакытта райподан кибетләрне заманча итеп ремонтлауга, дизайн өстендә эшләүгә, суыткыч җайланмаларын, стеллажларны алмаштыруга средстволар бүленгән. Предприятиенең гастрономы бүген шуның мисалы. Бу эш алга таба да алып барылачак.*

**-Минталип Салихович, гомумән карасаң, производство хәрәкәттә, эш бара, эшләгәннең ашы да булырга тиеш кебек. Нәтиҗәлелекне күтәрүдә төп тоткарлыклар нинди? Алардан чыгу юллары күренәме?**

Салымнарның басуы, һәр предприятие түбәсенә төшкән кылычтай, бездә дә төп проблема бүген. Республикада таләп ителә торган барлык салымны да бернинди ташламаларсыз түлибез, аеруча милек салымы зур сумманы тәшкил итә. Икенчедән, сәүдә чеклары белән эшләү дә зур югалтуга илтә: бердән, товар әйләнеше акрыная, икенчедән чекларга товар 15 - 20 процент дисконт белән (ягъни кимetелеп) бирелә, өченчедән, Казанда чекларны башка товарга алмаштыру процессы мораль яктан да зур киртәләр үтүне таләп итә.

Һәм, әлбәттә, мәҗбүри чыгымнар күплеге зур проблема. Шул сәбәпле товарга, продукциягә бәяне кую мәсьәләсендә базар, конкуренция таләпләренә өлгереп җитү кыенлаша.

Шуңа карамастан, райпо хезмәткәрләре базар алдында тез чүгәргә җыенмыйлар. Үз алдыбызга куелган бурычларны хәл кылуда яңа юлларны эзләүне дәвам итәбез. Ике ай элек әйләнештәге средстволарны халыктан заем алып эшләү аркасында арттыру да эшне бераз алга җибәрде. Заемны кертергә теләүчеләр булса, рәхим итегез, бездә процентлар банктагыдан югарырак, товар әйләнешеннән 3 проценты заемчыга ай саен түләнә. Кертелгән заемны бер атна эчендә кире алырга да мөмкин.

Тәҗрибәле 4 - 5 хезмәткәрдән торган коммерция бүлеге, ягъни маркетинг хезмәте оештыру система эчендә контрольне дә, тәртипне дә ныгытты.


Барлык чыгымнарны (транспорт, телефон һ.б.) киметү максатында лимитка куйдык.

**- Алда әйтелгән кыенлыклар күп кешене кыскартырга мәҗбүр итте сездә. Тагын да булачакмы алар?**

- Былтыр ел башында бездә 1115 кеше исәпләнсә, хәзер җәмгыятьтә барлыгы 760 кеше эшли. Дөрес, халыкның эш урынын саклап калу өчен тегү цехын киңәйттек. Шулай да, ничек кенә аяныч булмасын, алга таба да 20 процентлап хезмәткәр һәм ИТРны кыскартырга мәҗбүр булачакбыз. Әлбәттә, кыскартулар аттестация нигезендә тикшерелеп һөнәри яраклылыгын акламаганнарга янаячак.

**- Минталип Салихович, предприятиенең бүгенге кризис хәле озакка бармас дигән өметтә калып, сезгә уңышлар телибез.**

**Әңгәмәдәш**
**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**



***Андреевка көндәлек ихтыяҗ товарлары кибете авылдагы 636 кешегә хезмәт күрсәтә. 1975 елдан бирле кибетнең мөдире дә сатучысы да булып Роза Фатыйховна Мөхетдинова эшли. Ул кооперация - сәүдә системасына 1970нче елларда районда оештырылган кибет - мәктәптә белем алып килә. Эшетынгысыз - үзвакытында товарын ташып торуын кайгыртырга, халык ихтыяҗын өйрәнергә, кеше белән аралашуда итәгатьлелек, җылы мөнәсәбәтне югалтмаска... Татар кызына рус - чуваш авылына килеп төшкәч тел, гадәт мәсьәләләренә күнегү проблемасы да килеп баса.***

***Бүген болар барысы да артта калды инде. Шул авылда гаиләсе төпләнде, ике бала үстерәләр. Соңгы вакытта базар шартлары товар әйләнешенә тискәре йогынты ясаса да, Роза ханым киләчәккә ышанычын югалтмый. Быелның алты аенда товар әйләнешен 192 мең сумга җиткерде ул, авылның һәр кешесенә исәпләгәндә 300 сумлык әйбер сатып, планны 105 процентка үтәде.***

***Н.АЗИЗОВ фотосы.***

# ЙӨЗЕНДӘ - НУР, КҮҢЕЛЕНДӘ - ИЗГЕЛЕК

Рәхимә ханым Таһировна - яшьтән үк Нурлатка килеп төпләнгән, шатлыгын да, кайгы - борчуларын да, дус - ишләрен, туганнарын да монда тапкан чирмешәнлеләрнең берсе.

Сабыр холыклы, бераз оялчанрак та, әмма күңеле белән ихлас аралашуга омтылган яшь кыз шикәр заводына эшкә килеп керә. Ләкин үзен эзләү аны Октябрь райпосының мәктәп - кибетенә илтә. Менә шуннан, 1975 елдан башлана аның сәүдә өлкәсендә, азык - төлек товарлары сату нокталарында хезмәте.

Төрле вакытлар була эштә, халык белән һәрдаим тыгыз элемтәдә торганда кешелекле, ихлас күңелле булып кала белү, җаныңны кырыслыкка бирештермәү бик мөһим бу очракта. Клиентлар сизгер, холкыңдагы уңай һәм тискәре якларны, кәефеңне бик тиз тоеп алалар. Сатучының аңа мөгамәләсе кайчак күпне хәл итә бит. Рәхимә Таһировна да күңелсезлекләрне йөзенә чыгармас, һәрвакыт ачык, якты күңелле, һәрнәрсәне объектив күзлектән чыгып хәл итә. Якыннарының кыенлыклар килгәндә киңәшләшергә аның янына ашыгулары шуның белән аңлатыла да. Аның юмарт күңеле тынычландыра, төпле киңәшләре алга таба яшәргә өмет уята.

“Кеше көчле рухлы булырга тиеш, - дип уйлый ул. - Ә аның өчен ходайга табыну, дин тоту бик әһәмиятле”, - ди. Нәкъ шундый тормыш фәлсәфәсе аңа яшәргә, авыр чорда уңыш белән эшләргә этәреш, стимул бирә дә.

Ике иптәше белән ул эшләгән кечкенә генә кибетнең яртыеллык күрсәткечләре, шартлар ничек кенә кырыс булуга карамастан, үзеннән күпкә зурракларныкын шактый артта калдырды.



**РӘСЕМДӘ: АТП янында урнашкан 13нче кибет сатучысы Р.Зәйдуллина.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

*«Ялгызларны да языгыз»*

## БАР ИДЕ ЯШЬ ЧАКЛАР...

“Дуслык”та “Ялгызларны да языгыз” дигән мәкалә укыдым. Әйе, алар да ярдәм һәм терәк тоеп яшәргә телиләр, ләкин аларга язмышын уртаклашыр кеше юк. Менә мин дә гомерем буе ялгызым яшәдем. Яшьлегем сугыш чорына туры килде - миңа ул вакытта 16 яшь иде. Без Мамык юлын төзүдә эшләдек - кул көче белән таш ваттык, иң белән күтәреп туфрак ташыдык. Ә инде 22 июнь иртәсендә авыл гөр килде. Гаиләләр фронтка китүче ирләре белән исән килеш бәхилләштеләр... Озак та үтми "кара кәгазь"ләр килә башлады. Хатын - кызлар авыр кичерешләрдән сыгылдылар, ә без, яшьләр, көне - сәгате белән олыгайган кебек булдык - ялны да, бәйрәмнәрне дә оныттык. Урак урдык, көлтә бәйләдек, суктырдык, амбарларга икмәк ташыдык - бер эштән дә чирканмадык. Әле дә хәтерлим, бездә урып җыю вакытына Казаннан килгән Дьяконов фамилияле уполномоченный бар иде. Шул безгә: "Кызлар, мин сезгә йоклап алыр өчен 60 минут вакыт бирәм",- дия иде. Без шунда ук ашлык көшеләнә ташланабыз һәм үлгән кебек йоклап китәбез. Ә инде сәгать теле үзенең гадәти юлы белән бер әйләнеп чыгуга - эшкә дә тотынабыз. Каян шулкадәр көч табылгандыр. Ярым ач хәлдә йөри идек бит без. Ә кичләрен кемнең ничек эшләгәнен белү өчен идарәгә керәбез, фронтка - таныш түгел сугышчыларга өчпочмаклы хатлар язабыз.

Язын ташу вакытында Нурлатка чәчүлек орлыкка бара идек - мин Покровкада яши идем - җәяү, юеш чабаталар киеп, туңган кулларга бәрәңге көлчәсе тотып юлга чыга идек... Безнең яшьлек менә шулай узды.

Миңа тормыш юлдашым булырдай кеше дә очрамады - хыялымдагы ул егет, мөгаен, яу кырында башын салгандыр. Мин 53 ел буе эшләдем, ә гомерем ахырында, кем әйтмешли, ярык тагарак янында калдым. Фатирым иске, уңайлыклары юк, ишеге чалшайган - ә Нурлатта нинди генә “хан сарайлары” төземиләр...

Сезгә сүзем шул: әниләрегезне искә төшерегез, аларның ничек яшәве белән кызыксыныгыз, башкаларны да онытмагыз. Миңа инде 74 яшь, ләкин күңелемдәге өметемне өзмим - гомер ахырында булса да кешеләрчә яшисе килә. Ялгызлар да шундый ук кешеләр бит. Һәм бу - тормыш хакыйкате.

**А.КАРАНДАЕВА,**
**Нурлат шәһәре,**
**Нефтьчеләр урамы.**

## *Тәҗрибә адреслары*

***Билгеле булганча, безнең район соңгы бер - ике елда республикада күп кенә алдынгы тәҗрибә үрнәге күрсәтүче булды һәм безнең тәҗрибәне өйрәнергә әле дә күп җирләрдән киләләр. Шул исәптән былтыр бездә Липецк өлкәсе вәкилләре дә булып киткәннәр иде. Камилләшүнең чиге юк дигәндәй, башкаларның да алдынгы казанышларын белүнең артыгы юк. Менә шул ук Липецкида да игътибарга лаек мисаллар бар икән. Түбәндәге язма шул хакта сөйли.***

# БАРЛЫК ТАРМАКЛАР ДА ТАБЫШЛЫ

**Әгәр дә маллар үзара мәгълүмат алмаша алсалар, алар Липецк өлкәсендәге чикләнгән җаваплылыктагы "15 лет Октября" ширкәтендәге терлекләргә көнләшеп карарлар иде! Ике рәтле абзарларда җылы, якты, чиста һәм коры. Идәннәргә дезинфекцияләү һәм һаваны "киптерү" өчен известь таратылган. Ә утлыклардагы хуш исле печән - сыерларның алларыннан калганчы ашарга җитәрлек.**

Хуҗалыкның җиде бүлекчәсендә дә ферма бар, шуларның бишесе - сөт фермалары. Һәм һәркайда да "өч катлы" идәннәр -цемент өстенә имән такталар җәелгән, ә аның өстенә салам таратылган.

Күптән түгел шулай монннан бозау сатып алган күрше хуҗалыктан шалтыраталар:

- Кызык та иттегез сез безне: бозавыгыз бөтенләй ятмый бит.

- Ә сез аның астына салам җәйдегезме соң?

- Юк, ә нигә?

- Саламда йокларга күнеккәнгә күрә ятмый [illegible] инде ул.

Хуҗалыкта әзерләнгән [illegible]лык салам маллар астына таратуга китә. Ә утлыкларда печән җитәрлек. Күпьеллык үләннәр 1200 гектар монда. Костер кырлары да бар, әмма люцерна һәм костер, клевер һәм овсяница катнаш басулар күбрәк.

Беренче елны күбесенчә клевер печәне туплыйлар, ә икенче елны, инде клевер сирәкләнгәч, овсяницаны күбрәк җыялар. Вика - солы катнашмасын авыр туфраклы кырларга чәчәләр: аммиак суы белән дә тукландырып куйсаң, бу культура андый җирдән курыкмый.

Үләннәрне, бер - ике [illegible] кипшенсен һәм шикәр тупласын өчен тезем дә калдырып аеры ысул белән генә чабалар. Шуннан менә бер дигән сенаж килеп чыга. Ә инде сөт сыман - балавызсыман өлгерешкә кадәр үстерелә торган кукурузны беренче салкыннардан соң җыеп алырга тырышалар. Ул чакта силосның ачылыгы азрак була, үзеннән ипи исе килеп тора.

Былтыр кышка монда сыер башына 6 тонна печән әзерләп куйганнар. Бердән аны гектарыннан 40ар центнер үстерсәләр, икенчедән, түкми - чәчми җыеп алу чарасын күргәннәр, үләннәрнең иң туклыклы өлешен камыл арасында калдырып әрәм итмәгәннәр. **Һәм моның сере - төргәкле пресслар куллануда.**

Хуҗалык җитәкчесе Николай Дмитриевич Еремеев башта печән җыю мәшәкате белән иза чигә. Я яңгырлар комачаулык итә, я инде өеп куйган эскертләрне кабат таратып җилләтергә туры килә. Ул чакта бит инде печәннең исеме генә кала. Һәм директор төргәкле җыйгыч - пресслагычлар юнәтү өчен мөмкин булганның барысын да эшли. Шушы гына да элеккеге үк мәйданнардан печәнне 50 процентка күбрәк әзерләргә мөмкинлек бирә. Эскерт өйгечләрне печән төргәкләрен КамАЗга төяүгә көйлиләр. Әнә шулай печән ферма тирәсендәге ангарларга кайтарып өелә. Бөтен саламны да шунда ук, ангарларга урнаштыралар.

Былтыргы көзге туктаусыз яңгырлар Липецк хуҗалыкларына шикәр чөгендерен тулысынча җыеп алырга ирек бирмәде. Ә менә "15 лет Октября"да чөгендерен дә җыеп алдылар, туңга сөрүне дә бетерделәр. Еш кына тракторлар басуга, җир кипшенүгә төнлә дә чыккаладылар. Яннарында "летучка"лар дежур торды. Ә төнгә барлык техника түбә астына куела.

Хуҗалыкта гектардан 300 центнер шикәр чөгендере җыеп алдылар, ә 9 мең тонна чөгендердән 700 тонна шикәр чыкты. "Валюта резервы" дип йөртә аны Николай Дмитриевич. Әле бит моннан тыш күпме жом һәм патока бирә ул хуҗалыкка. Сыерларның кышкы көнлек рационында - 20 килограмм силос, 15кг. - жом, 3 килограмм концентрат азык, патока һәм кирәгенчә печән. Шулай итеп, беренчедән, печән концентрат азыктан артып та китә, ә икенчедән, соңгысы 50 процент арпа, 40 процент солы һәм 10 процент борчактан тора. Менә сезгә туклыклы матдәләрнең балансы. Барлык концентрат азыклар да тозландырып кына бирелә, аларны иртән парлап куялар да, кичтән өләшәләр. Сыер башына барлыгы 14 азык берәмлеге чыга. Ә кышка бер терлеккә 40 центнер азык берәмлеге туплап куелган иде....

***Язманың бу өлеше - алдынгы хуҗалыкта терлекчелекнең азык базасын ныклы итүгә ничек ирешүләре хакында. Аңлашылганча, анда тупас азыкларны төргәкле пресслар ярдәмендә мулдан һәм туклыклы килеш туплап куялар икән. Бәхеткә, район җитәкчелегенең зур тырышлыгы белән андый пресслар быел безнең районга да кайтарылды, һәм бүген хуҗалыкларда ике дистә шундый агрегат бар инде һәм күпчелек хуҗалыкларда алар уңышлы кулланыла. Ә менә пресснең әһәмиятен аңлап бетермәүчеләргә бу язманы тагын бер тапкыр игътибар белән укып чыгарга киңәш итәбез. Ә инде "15 лет Октября" хуҗалыгында терлекчелектә нинди нәтиҗәләргә ирешүләре, аларның башка тармаклардагы казанышлары турында - язманың икенче өлешендә сүз булачак.***

## *Безнең интервью*

# ҮЗ КӨНЕҢНЕ ҮЗЕҢ КАЙГЫРТ

**АДЛЕР ИБРАҺИМ УЛЫ ГАЗИЗУЛЛИН исеме безнең укучыларга яхшы таныш. Ул - "Росгосстрах - Татарстан"ның Нурлат филиалы директоры. Безгә һәрдаим очрап торган гади көндәлек проблемалар аңа да мәгълүм. Билгеле, аларны ничек хәл итү турында төпле киңәшләр дә бирергә сәләтле ул. Безнең әңгәмәбез дә шул хакта.**

**- Адлер Ибраһимович, баласына рәтле белем бирү, лаеклы итеп туй мәҗлесен үткәрү, мөстәкыйль тормыш башлауда яшьләргә тиешле ярдәм күрсәтү өчен нишләргә бүген?**

- Беләсезме, мин һәрвакыт нәрсә дим? Хөкүмәткә, социаль - тәэминат органнарына зур өметләр баглый торган заманнар артта калды. Бүген үзе һәм балалары турында һәркем үзе кайгыртырга тиеш. Димәк, киләчәкне күрә белергә кирәк.

**- Тиенләп җыяргамы акчаны?**

- Тиенләп оекка җыю - өметсез эш. Булган акчаларыңны бәясе төшмәслек итеп урнаштыру мөһим. Мин бу очракта тормышны страховать итү турында сөйлим. Безнең компания гражданнар белән тормышны страховать итү килешүен ай саен взнослар түләү шарты белән төзи. Аңлашыла ки, мондый килешүне тизрәк төзесәгез, шулай ук үзегезгә кирәкле сумманы тизрәк туплый аласыз.

**- Сез бит әле инфляция турында сөйләдегез!**

- Без гражданнарның взносларын инвестицияләрдән кергән керемнәр исәбенә индексациялибез - страховой компаниянең үзенчәлеге дә шунда. 1995 елдан компаниябез индексация процентын ике тапкыр күтәрде, шул нигездә клиентларның акчаларын кыйммәтен югалтудан саклап калды. Мисал китерәм. Уртача 40 яшьлек ир - ат 3 елга страховой килешү төзегәндә ул 3 ел өчен 784 сум 80 тиен акча түли, ягъни ай саен 21 сум 80 тиенгә төшә. Килешү вакыты үткәч, ул аны мең сум итеп ала. Әгәр дә килешүне 5 һәм аннан да күбрәк елга төзесә, страховать итү шартлары аның өчен тагын да отышлырак булачак. Шул мисалдан кайсы вакытка күпме акча туплый алачагыгызны санап чыгарырга мөмкин.

**- Мәсәлән, улыңны яки кызыңны абруйлы коммерция вузында укытыр өчен...**

- Әйе, бүген бит әйбәт һөнәргә ия булу арзан түгел. Тик кешенең кайгысы бу гына түгел бит әле! Күбесе ял итү турында хыяллана, кемгәдер югары сыйфатлы дәвалану кирәк. "Тасфир" сезгә санаторий - курорт дәвалавы һәм чит илдә әйдәп баручы белгечләрдән консультация алу, бик кирәк булганда операциягә баруны да оештыра ала. Барысы да клиент теләгеннән тора. Предприятие җитәкчеләре үз хезмәткәрләрен бездә страховать итсәләр изге эш эшли алырлар иде. Бу суммалардан пенсия һәм бюджеттан тыш фондларга взнослар алынмый, ул чыгымнарның 1 проценты реализацияләнгән товар күләменнән (яки хезмәт күрсәтүдән) үзкыйммәткә кертелә, предприятиеләргә халык турында кайгырту файдага гына димәк.

**- Адлер Ибраһимович, страховать итү компаниясе инвестицияләүгә әверелә дигән уй туарга мөмкин.**

- Әйдәгез карыйк әле, акча җыю максатында страховать итүнең банкка взнос кертүдән нинди аермасы бар икән?

Төп аерма килешүдә күренә. Беренче пунктларда ук страховать ителүченең страховой вакыйга булган очракта килешүдә каралган сумманы алуга хокукы теркәлгән. Баштагы тегe мисалга кайтыйк. 40 яшьлек ир - ат килешү төзеде, взнос түли башлады (6 ай, 1 ел һәм тагын да), ягъни килешү срогы үтмәде, ләкин страховой вакыйга килеп чыкты (мәсәлән, страховать ителүче вафат булды) ди. Нәтиҗәдә, бөтен акча, ягъни мең сум, васыять ителгән кешегә түләнә. Ә банк бу вакытка җыелган сумманы гына түли. Икенче төрле әйткәндә, сез акча туплау страховой килешүе төзегәндә, иң беренче чиратта, үзегезне күрәчәктән яклыйсыз. Шул ук вакытта ялга яки дәвалануга, балаларны укытуга яки туйны үткәрүгә акча да җыясыз. Файдалымы кеше өчен? Һичшиксез!

**- Адлер Ибраһимович, сез гомер буена страховать итү турында да килешү төзисез. Бу нәрсә?**

- Әйе, бала туугa ук һәм 70 яшькәчә гомер буена страховать итү турында килешү төзибез, яше кечерәк булган саен страховой взнос та азрак кирәк. Мисал өчен, 1 яшьлек малайны мең сумга страховать итү өчен барлыгы 17 сум 70 тиен, 40 яшьлек ир - атка - 140 сум 30 тиен, 60 яшьлеккә - 363 сум 70 тиен взнос түләргә кирәк. 40 яшьлек хатын - кызга - 68 сум 40 тиен, 60 яшьлеккә - 242 сум 10 тиен. Алда әйтелгәнчә, страховой вакыйга булган очракта страховой акча тулысынча түләнә. Гомер буена страховать итү килешүен 500 сумнан алып 30 мең сумгача төзергә мөмкин.

Безнең фирма Россиядә бердәнбер дәүләт страховой компаниясе һәм шуңа күрә иң ышанычлылардан исәпләнә. Без һәрвакыт халыкның тормышын, мал - мөлкәтен, транспортын, төзелеш - корылмаларын һәм башкаларны страховать итәргә шатланып риза булабыз һәм страховать итүнең киң төрләрен тәкъдим итәбез. Килегез, үкенмәссез.

**Әңгәмәдәш**
**Д.ТӘМАЕВА.**

# МАЛЫҢ ҮРЧЕМЛЕМЕ?

## *Район хуҗалыкларында алты айда дуңгызлардан үрчем алу күрсәткечләре.*

**Саннарның беренче баганасы - барлык үрчем, икенчесе - һәр йөз анага күчереп исәпләгәндә.**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| "Родина" | 1760 | 793 | "Руслан" кооп. | 240 | 289 |
| М.Җәлил исем. | 850 | 599 | Хафизов исем. | 1670 | 253 |
| Кузнецов исем. | 2230 | 463 | "Комбайн" | 305 | 250 |
| "Нур" кооп. | 370 | 446 | "Заря" | 136 | 247 |
| "Чулпан" | 979 | 431 | "Татарстан" | 900 | 230 |
| "Рассвет" | 2780 | 402 | Мичурин исем. | 714 | 225 |
| "Таң" | 219 | 359 | "Киекле" | 660 | 222 |
| Синдряков исем. | 3233 | 330 | "Үрнәк" | 123 | 195 |
| Нефтебаза ярд. хуҗ. | 700 | 330 | "Нива" кооп. | 150 | 181 |
| Сөт - май комб.ярд. хуҗ. | 500 | 311 | Дуңгызлар симертү | | |
| "Төрнәс" | 1212 | 309 | буенча хуҗалыкара | | |
| "Сөлчә" | 430 | 309 | берләшмә | 540 | 138 |
| РСУ ярд. хуҗ. | 900 | 302 | "Алга" | 150 | 65 |
| "Заветы Ильича" | 701 | 292 | | | |
| Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 700 | 292 | **Район буенча** | **23152** | **319** |

Район буенча 6 айда алынган дуңгыз балалары узган елдагыдан күбрәк булса да, хуҗалыкларның күрсәткечләре арасындагы чуарлык зур булу быел алга куелган максатка ирешү авыр булачагын раслый. Кузнецов исемендәге хуҗалыкта быел дуңгыз балалары былтыр алты айдагыдан 500 башка диярлек, "Родина"да 160 башка күбрәк алынган, елның - елында иң күп үрчем алучы Синдряков исемендәге, "Рассвет" хуҗалыклары былтыргы дәрәҗәне саклап калган бер үк вакытта, Хафизов исемендәге хуҗалыкта 350, "Төрнәс"тә 220 башка чигенеш ясадылар. Ә бит болар - дуңгызлар чагыштырмача ишле булган хуҗалыклар. Мичурин исемендәге хуҗалыкта да быел чигенеш зур. Дөрес, "Киекле", "Татарстан", "Чулпан", нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларында алга китеш бар, әмма район күрсәткечен тагын да күтәрер өчен бу гына аз әле. "Үрнәк", "Заветы Ильича", "Руслан" һәм "Нива" кооперативлары һәм кайбер башка хуҗалыклар дуңгызлардан үрчем алуда һич югы былтыргы дәрәҗәдә генә эшләсәләр дә, гомуми нәтиҗәләр шактый югары буласы иде. Кызганычка каршы, аларның соңгысында былтыргы күрсәткечнең яртысы да юк, беренчесендә дә үрчем узган елдагыдан икеләтә диярлек ким.Әле бит малларның үлем - китеменә юл кую аркасында да шактый югалтулар кичерелә.

Хәзер төп бурыч - җәйге үрчемне исән - сау карап үстерү һәм малларны көзге - кышкы чорда абзарда балалатуга әзерләү.

# Тәлгат Галиуллин

# ГОМЕР ТӘЛГӘШЛӘРЕ

## ӘНИ ҺӘМ АНЫҢ МОХИТЕ

**(Дәвамы. Башы 65-67, 71-79нчы саннарда).**

Безнең гаилә нәкъ ун кешедән, әти белән әни һәм сигез баладан гыйбарәт.

Һәр гаиләнең үз яшәү рәвеше, башкалар күзенә кылчык булып кереп тормаган "милли колориты" була. Шагыйрь әйтмешли, күрә белергә күңел күзе генә кирәк.

Әни реклама яратмый, кәпрәю, масаю аның холкына туры килми. Шулай да ул үзенең хәлле нәселдән, ак куллы (укы: кулак) токымнан чыкканын онытмый. Сугыштан соңгы чорда, хәерчелек, җитешмәү ээзәрлекләгәндә дә, аңа үткәне рухи таяныч, терәк була.

1917 ел түнтәрелешенә кадәр авылның кыл уртасында кызыл кирпечтән салынган ике ташпулатның берсен аның туганнары салдырган, әтисе - Шәфигулла агачтан кирәк - ярак әйберләр ясауга оста булган, һөнәренә башкаларны өйрәткән, тирә - юнь авылларны чана, көпчәк, камыт, агач көрәк, киле, имән мичкәләр белән тәэмин итеп торган. Хәзер дә әнинең туганнарын алтын куллылар, диләр. Шәфигулла картның балалары, оныклары - авылда иң оста балта осталары, мич чыгаручылар. Техника чоры җиткәч, иң алдынгы комбайнчыны да шул нәсел бирде.

Табигый ки, ярлы - ябагага - шариковларга йөз тоткан сәвитләргә булдыклы кешеләр кирәкми. Ике йөз йортлы Кычытканлы авылыннан биш кулак "тапшырырга", дигән разнарядка килә. "Безнең авылда ул чаклы бай кеше юк, санны киметегез",- дип ялваруларның файдасы тими. Яхшы йортлы, бигрәк тә калай түбәле, берничә ат тоткан кешеләрне кулакка чыгарып, бар байлыгын талап, әрәм - шәрәм итеп, шул исәптән Шәфигулла бабайны да "төзәлергә" хезмәт фронтына алып китәләр. Бабай сугыш алдыннан туган авылына үләргә генә кайта.

Гаиләдә әти сүзе - үтәлергә тиешле канун, әнинеке - ачыкламыш, юнәлеш, өстәмә аңлатма. Соңгысының төп чарасы - сиземләү, вакыйга - хәлләр агышын алдан күрә белү, "кризис"ка җиткермәү. Филнең дөядән биегрәк икәнен аңлатып торасы түгел.

Әти телгә, сүзгә оста, җор кеше булса да, хискә бирелеп, туарылып китүне ир - ат өчен мәртәбә санамый. Терәге - әни. Ул аның янында, дәртле, үз бәясен белгән күркә төсле, умыртка баганасын турайтып, аркасын катырып утыра.

Хәзерге төшенчә белән әйтсәк, әти - хуҗа, абруй, әни - түбә (крыша). Өйдә кемнең ахыр өстенлеген сирәк кеше белә. Мин үзем дә аның серенә гаилә белән яшәп, ике малай үстергәч, фәннәр докторы булгач кына, азмы - күпме төшенә башладым. Чөнки ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәттән дә катлаулырак сәнгать, буталчыграк фән юктыр дөньяда. Генетика, нисби теория, фараз кебек гыйлемнәрнең барысы да икенчел.

Әти - тиз кызучан, яна, шартлый, сүтелә (үзе беркадәр артист та, тышкы сурәтне ярата), әни - ут сүндерүче. Инде бүртелгән тал чыбыгы безнең аркага төшәргә торганда, әни кечкенә, хәрәкәтчән бармаклары белән хәләл җефетенең иңнәренә орынып ала, әти шундук ярларына кайтып төшә, өянәге тынычлана.


Ике яшь бала белән тол калган, кайгыдан күзләре сукырайган Камилә әби әнине онтугызы тулар - тулмас килеш кияүгә бирә. Вак яңгырлы, тымызык бер иртәдә әни яңа хөкүмәткә хезмәткә күчкән, кулларында балта тота белмәсәләр дә, күз белән телгә үткен, язу - сызу эшенә һәм сөйләү хасиятенә маһир Галиуллиннарга килен булып төшә.

Аларның бер - берсен аңлап, хөрмәт итешеп, дустанә яшәүләрен тою безнең өчен таяныч, үрнәк - өлге булды.

**(Дәвамы бар).**

## КЕМГӘ КҮПМЕ ЙОКЛАУ КИРӘК?

4 - 5 сәгать йоклауга Наполеонның йокысы туя торган була. Ә Лондонда яшәүче бер шәфкать туташына 49 минут черем итеп алу да җиткән - ул гомере буе шулай аз йоклап яшәгән. Ә кайберәүләргә 12 сәгатьлек йокы да аз. Йокы "симертүчеләр"нең күбесе көзге айларда - октябрь - ноябрьдә туганнар, ә җәйге айларда туганнар - азрак йоклаучан. Хатын - кызлар ирләргә караганда 1 сәгать артык йоклыйлар.



***

Планк исемендәге нимес институты галимнәре раславынча, кешегә төнге йокы гына җитми: ул көненә өч тапкыр - 9, 13 һәм 17 сәгатьләрдә черем итеп алырга тиеш. 10 - 15 минут башыңны беләгеңә салып черем итеп алу да хәл кертеп җибәрә. Штирлиц та, хәтерләсәгез, чираттагы хәрби бурычын үтәгәч, машинасында чирек сәгать черем итеп ала.

***

Япон галимнәре, авыз ачып иснәү баш мие эшчәнлеген яхшырта һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыра, дип раслыйлар. Теле - радио аппаратлары җитештерә торган бик күп заводларда эшчеләр 15 минут саен туктап, кулларын югары күтәреп, команда белән 30 секунд иснәп алалар икән.

***

Калифорния университетының бер төркем психологлары әйтүенчә, кеше өчен йокы симертү дә, аз йоклау да зарарлы. Тикшерүләр шуны күрсәткән: "йокы чүлмәкләре" һәм 4 сәгатьтән дә ким йоклаучы кешеләр вакытыннан иртә үләләр икән.

***

Пьер Давийо (француз галиме), кешеләрнең йоклаганда нинди торышта булуларына карап, кызыклы нәтиҗәләр чыгарган. Йөзтүбән ятып йоклаучылар үз һөнәрләреннән канәгать булмаучылар, чалкан ятып йоклаучылар көчле ихтыярлы һәм тормышта уңышка ирешүчеләр, ә инде мәче кебек бөгәрләнеп, мендәрләрен кочаклап йоклаучылар моң - сагышка бирелүче һәм иркәләү - наздан мәхрүм кешеләр икән. Пессимистлар одеялны башларыннан ук бөркәнеп яталар.

***

Галимнәрнең әйтүе буенча, бик күп авиаһәлакәтләр, Чернобыль фаҗигасе, "Челленджер"ның (АКШ галәм корабы) януы да йокы туймау белән бәйле. Киләсе гасырда кешелекне СПИД кебек үк куркыныч - йоклый алмау афәте көтә.

**("Мәдәни җомга"дан).**


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Чимкент шәһәрендәге 1 бүлмәле фатирны - Нурлатта шуңа тиңгә.** Тел.: 3-92-11.

***

**2 бүлмәле фатирны - өстәмә түләп ике берәр бүлмәлегә.** Адрес: Октябрьнең 60 еллыгы ур., 23 - 8, көндезге 1дән кичке 5кә кадәр.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Ирек Һади улы Билалов исеменә шофер таныклыгы табучының бүләк бәрабәренә Тельман ур., 9 - 29 адресы буенча кайтарып бирүен сорыйбыз.**

***

**Миннәҗип Минсафа улы Шәһидуллин исеменә документлар табучының бүләк бәрабәренә Куйбышев ур., 94 - 4 адресы буенча кайтарып бирүен сорыйбыз.**

***

**61нче мәктәпнең 10 "А" классын 1978нче елда тәмамлаучыларның очрашуы быелның 15 августында була.** Белешмәләр өчен тел.: 5-42-54.

***

**Йомшак җиһаз ремонтлыйбыз.** Тел.: 5-19-80.

***

**Куйбышев урамында гыйбадәт йорты ябылу сәбәпле барлык сораулар белән дә К.Маркс проспектындагы Илья пәйгамбәр чиркәвенә мөрәҗәгать итәргә.** Тел.: 5-32-63.

***

**Ике кешедән торган гаиләгә барлык уңайлыклары белән ике бүлмәле фатир кирәк.**

Тел.: 2-28-88 (18 сәг.тән 20 сәг.кә кадәр).

***

**Фатир эзлим.**

Тел.: 2-23-48 (көндезге 1дән кичке 9га кадәр).

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга - 17 нче июль көнне, көндезге сәгать 11дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән

№ 00164 - 30 лицензия.


## КОТЛЫЙБЫЗ!

Якты Күл авылында яшәүче **Хөсния Һади кызы Бикиевáны** чын күңелдән туган көне белән котлыйбыз.

Синең өчен һәрчак аяз зәңгәр һава,
Синең өчен ләйсән сыман карлар ява,
Синең өчен гөлләребез чәчәк ата,
Синең өчен сайрап туймый сандугач та.
Исемең яңгырый бер моң булып
тирә - якта,
Без бәхетле бу дөньяда, әниебез,
син бар чакта.

**Тормыш иптәшең, балаларың, килен - кияүләрең, оныкларың исеменнән кызың Әлфия.**


## БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ

**Совет ур., 189 адресы буенча аз кешеле гаиләләр йортында ике бүлмәле фатир.** Тел.: 2-21-55.

***

**Димитров урамында 18нче йорт.** Тел.: 3-12-56.

***

**1996 елгы ВАЗ - 21213.** Тел.: 5-33-61.

***

**Ашыгыч төстә "Урал" мотоциклына запас частьлар.** Тел.: 2-16-06, теләсә кайчан.

***

**Телевышка тирәсендә капиталь гараж, арзан.**

Адрес: Школьная ур., 11 - 26.

***

**ВАЗ - 21065.** Тел.: 5-27-96.

***

**АОГВ - 29 газ казаны, газ исәплләгеч.** Тел.: 2-22-49.

***

**ВАЗ - 21011.** Тел.: 5-19-80.

***

**Ашыгыч төстә 1997 елгы тентлы "Газель", "Опель - Кадет", кыйммәт түгел.** Адрес: Энгельс ур., 10.

***

**Чанада гараж.** Адрес: К.Маркс ур., 1 - 19.

***

**Ашыгыч төстә әфган поселогында йорт нигезе һәм төзү материаллары белән участок, 1997 елның декабрендә чыккан ВАЗ - 2110.**

Тел.: 5-17-78 яки 5-21-79, 5-11-22.

***

**1995 елгы ВАЗ - 21213 "Нива".**

Адрес: Мәктәп ур., 26 - 16, тел.: 2-17-01.

***

**УАЗ.** Тел.: 5-21-54.

***

**ВАЗ - 2105, кыйммәт түгел.** Тел.: 5-36-62.

***

**"Таврия" автомашинасы, чанада тимер гараж.**

Тел.: 2-23-73.

***

**Чанада гараж.** Тел.: 5-21-16.

***

**Ике бүлмәле фатир.**

Адрес: Красноармейская ур., 27 (теләсә кайчан).

**Каравыл Тавы кирпеч заводы меңен 600 сумнан кызыл кирпеч сата, пенсионерларга пенсия хисабына да бирелә. Аеруча мохтаҗларга, өстәмә түләү бәрабәренә, автохезмәтләр күрсәтелә.**

Тел.: 2-26-14.

**"Ак Барс" банкының Нурлаттагы өстәмә офисы Сезгә 1998 елның 14нче июленнән Нурлатта Мәктәп ур., 10 адресы буенча валюта алыштыру пункты эшли башлавы турында белгертә. Без сезне якшәмбедән кала һәркөнне иртәнге 9дан көндезге 1гә кадәр күрергә шатбыз.**

**Белешмәләр өчен тел.: 2-22-50.**


"Нурлатнефть" НГДУсы администрациясе һәм коллективы әтисе **Габдрахман Касыймовның** вафат булуы сәбәпле "Девон - Кредит" акционерлык банкының Нурлат филиалы управляющие Нурзия Габдрахман кызы Салахованың авыр хәсрәтен уртаклашалар.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2337 данә. 2911